КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 7 сентябрь г.Казань № 799

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкара программалар дирекциясе» автоном коммерциягә карамаган оешмасын төзү турында» 2016 ел, 5 май, 283 нче карары белән расланган «Халыкара программалар дирекциясе» автоном коммерциягә карамаган оешмасы уставына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкара программалар дирекциясе» автоном коммерциягә карамаган оешмасын төзү турында» 2016 ел, 5 май, 283 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 26 ноябрь, 875 нче; 2018 ел, 29 сентябрь, 886 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Халыкара программалар дирекциясе» автоном коммерциягә карамаган оешмасы уставына, 2.3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2.3. Автоном оешма түбәндәге эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырырга мөмкин:

халыкара, бөтенроссия, төбәкара һәм республика чараларын, шул исәптән социаль юнәлешле чараларны һәм проектларны оештыру һәм уздыру;

массакүләм мәгълүмат чаралары аша, материалларны максатчан тарату, презентацияләр, конгресслар, саммитлар, «түгәрәк өстәл» утырышлары һ.б. үткәрү юлы белән Татарстан Республикасының инвестицион җәлеп итүчәнлеге турында мәгълүмат әзерләү, бастырып чыгару һәм тарату;

инвестиция өлкәсендә квалификацияне күтәрү буенча семинарлар, тренинглар, форумнар һәм башка чаралар үткәрү;

реклама эшчәнлеге;

эшчәнлекнең уставтагы максатларга ирешү өчен кирәкле башка төрләре.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин